| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.03.2015 Казань ш. № 10-6/кс

***2015 – 2018 елларга «Экосистемы» ҖЧҖе тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында***

«Коммуналь комплекс оешмаларының тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ санлы Федераль законга, «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя кую нигезләре һәм тарифларны, өстәлмәләрне һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР бирә:

1. Ютазы муниципаль районының «ЭкоСистемы» ҖЧҖе тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны, билгеле бер календарь чорларына бүлеп, әлеге карарның 1 нче кушымтасындагыча билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 маеннан 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендә әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән тарифларның гамәлдә булу чорына Ютазы муниципаль районының «ЭкоСистемы» ҖЧҖе җитештерү программасының төп күрсәткечләрен әлеге карарның 2 кушымтасына нигезләнеп килештерергә.

4. Ютазы муниципаль районының «ЭкоСистемы» ҖЧҖенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 30 декабрендәге 1140 санлы карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

5. Әлеге карарда билгеләнгән каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Коммуналь комплекс

оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийлар системасын урнаштыру турында» 2014 елның 24 февралендәге 56 санлы боерыгы белән расланган коммуналь комплекс оешмалары товарларыннан һәм хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийларына туры килә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты карарына
1 нче кушымта
13.03.2015 № 10-6/кс

2015 – 2018 елларга
«ЭкоСистемы» ҖЧҖе тарафыннан билгеле бер календарь чорларына
каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № п/п | Коммуналь комплекс оешмасы, муниципаль берәмлек атамасы | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар сум/куб.м | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2015 елның 1 маеннан 2015 елның 30 июненә кадәр | 2015 елның 1 июленнән 2015 елның 31 декабренә кадәр | 2016 елның 1 гыйнва-рыннан 2016 елның 30 июненә кадәр | 2016 елның 1 июленнән 2016 елның 31 декабренә кадәр | 2017 елның 1 гыйнва-рыннан 2017 елның 30 июненә кадәр | 2017 елның 1 июленнән 2017 елның 31 декабренә кадәр | 2018 елның 1 гыйнва-рыннан 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән 2018 елның 31 декабренә кадәр |
| | Ютазы муниципаль районы | | | | | | | | |
| 1 | «ЭкоСистемы» ҖЧҖе* | 121,60 | 139,80 | 139,80 | 143,51 | 143,51 | 151,01 | 151,01 | 157,66 |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
2 нче кушымта
13.03.2015 № 10-6/кс

## Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендә «ЭкоСистемы» ҖЧҖе җитештерү программасының төп күрсәткечләре

| № п/п | Коммуналь комплекс оешмасы атамасы | 2015 елның 1 маеннан 2015 елның 31 декабренә кадәр | | | | | 2016 елның 1 гыйнварыннан 2016 елның 31 декабренә кадәр | | | | | 2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 31 декабренә кадәр | | | | | 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 декабренә кадәр | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре, мең куб.м | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре, мең куб.м | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре, мең куб.м | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре, мең куб.м | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) |
| | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү күләме, шул исәптән: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү күләме, шул исәптән: | | | | |
| | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка кулланучылар | |
| 1 | «ЭкоСистемы» ҖЧҖе* | 23,97 | 17,75 | 2,10 | 4,12 | 3128,70 | 23,97 | 17,75 | 2,10 | 4,12 | 3396,83 | 23,97 | 17,75 | 2,10 | 4,12 | 3531,32 | 23,97 | 17,75 | 2,10 | 4,12 | 3701,01 |

<*> - салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге